РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА
НОВОТИНЧАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ТИНЧӘЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 октябрь 2023 ел № 2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге
территориясендә каты көнкүреш
калдыкларын туплау мәйданчыкларының
реестрын һәм урнаштыру схемасын
раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясындагы 4 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары белән расланган Каты көнкүреш калдыкларын туплау һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге территориясендә каты көнкүреш калдыклар туплау мәйданчыкларының реестрын һәм урнаштыру схемасын расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле
авыл җирлеге башлыгы Мадышев Р.К.

ТР Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле
авыл җирлеге башлыгының
2023 елның «09» октябрьдәге 2 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге территориясендә каты көнкүреш калдыкларын туплау урыннары реестры

| № т/б | Контейнер мәйданчыгының хуҗасы (хуҗасы) (тулы исеме) | Каты көнкүреш калдыкларын туплау урыннарының (мәйданчыкларының) техник характеристикалары | Контейнер мәйданчыгы урнашкан урын | Контейнерлар саны | Чыгулар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Яңа Тинчәле авыл җирлеге | Өслеге- сууткәрмәүчән (бетон); мәйданчык мәйданы S=12 $м^2$; күләме -1,1 $м^3$ | Яңа Тинчәле авылы, Совет урамы (1 нче номерлы йортка каршы) | 3 | |
| 2. | Яңа Тинчәле авыл җирлеге | Өслеге- сууткәрмәүчән (бетон); мәйданчык мәйданы S=12 $м^2$; күләме- 1,1 $м^3$ | Яңа Тинчәле авылы,Тукай урамы (1 нче номерлы йорт янында) | 3 | |
| 3. | Яңа Тинчәле авыл җирлеге | Өслеге- сууткәрмәүчән (бетон); мәйданчык мәйданы S=6 $м^2$; күләме - 1,1 $м^3$ | Яңа Тинчәле авылы, Мәктәп урамы. ( 28 нче номерлы йортка каршы, авыл мәдәният йорты) | 2 | |